**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 8 июлендәге 2391 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә**
**1 мильгә йөгерү буенча Россия чемпионатын,**
**«Төнге Казан 2026» җиңел атлетика буенча**
**төбәк ярышларын уздыру, чараны әзерләү һәм**
**үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен**
**вакытлыча чикләү турында**

1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы «Юл хәрәкәте иминлеге турында»гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законнарга һәм 2009 елның 3 августындагы 43-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында»гы Татарстан Республикасы законына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 5 мартындагы 159 номерлы «“Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карары нигезендә, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, халыкны физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, Казан шәһәрендә җиңел атлетиканы популярлаштыру максатыннан:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәрендә 1 мильгә йөгерү буенча Россия чемпионатын, «Төнге Казан 2026» җиңел атлетика буенча төбәк ярышларын әзерләү һәм үткәрү вакытында әлеге карарның 1-4 номерлы кушымталары нигезендә транспорт чаралары хәрәкәтен чикләүне кертергә:

1.1.1. 2026 елның 8 июлендә 00:00 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 09:00 сәгатькә кадәр – Үзәк стадион парковкасында (Ташаяк һәм Кремль яр буе урамнары ягыннан);

1.1.2. 2026 елның 11 июлендә 00:00 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Уң як Болак урамындагы муниципаль автомобиль парковкаларында (Пушкин урамыннан Ташаяк урамына кадәр);

1.1.3. 2026 елның 11 июлендә 00:00 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Сул як Болак урамындагы муниципаль автомобиль парковкаларында (Ташаяк урамыннан Пушкин  урамына кадәр);

1.1.4. 2026 елның 11 июлендә 00:00 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Һади Такташ урамындагы муниципаль автомобиль парковкаларында (Марсель Сәлимҗанов урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр ике юнәлештә);

1.1.5. 2026 елның 11 июлендә 00:00 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Петербург урамындагы муниципаль автомобиль парковкаларында (Туфан Миңнуллин урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр ике юнәлештә);

1.1.6. 2026 елның 11 июлендә 17:00 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Меңьеллык мәйданында (Кремль дамбасыннан чыгу юлыннан Ташаяк урамына кадәр, бер юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.7. 2026 елның 11 июлендә 17:00 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр –  Ташаяк урамы буенча (Уң як Болак урамыннан Мәскәү урамына кадәр, ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.8. 2026 елның 11 июлендә 17:00 сәгатьтән 20:30 сәгатькә кадәр – Сул як Болак урамы буенча (Ташаяк урамыннан Таҗи Гыйззәт урамына  кадәр, хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.9. 2026 елның 11 июлендә 17:00 сәгатьтән 20:30 сәгатькә кадәр – Уң як Болак урамы буенча (Муса Җәлил урамыннан Ташаяк урамына кадәр, хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.10. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр –  Сул як Болак урамы буенча (Ташаяк урамыннан Татарстан урамына кадәр, хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.11. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр –  Уң як Болак урамы буенча (Пушкин урамыннан Ташаяк урамына кадәр, хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.12. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр –  Татарстан урамы буенча (Сул як Болак урамыннан Мәскәү урамына кадәр, ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.13. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр –  Пушкин урамы буенча (Островский урамыннан Сул як Болак урамына кадәр, ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.14. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр –  Һади Такташ урамы буенча (Туфан Миңнуллин урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр, ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.15. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Туфан Миңнуллин урамы буенча (Тихомирнов урамыннан Һади Такташ урамына кадәр, ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.16. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Петербург урамы буенча (Суконная урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр автомобиль юлында махсус киңәйтелгән урынны да кертеп, Туфан Миңнуллин урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр, ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.1.17. 2026 елның 11 июлендә 20:30 сәгатьтән 2026 елның 12 июлендә 02:30 сәгатькә кадәр – Марсель Сәлимҗанов урамы буенча (Пушкин урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына кадәр, ике юнәлештә хәрәкәтне туктатып тору);

1.2. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Физик культура һәм спорт комитетына (Л.З.Гарипов) әлеге чараны әзерләүдә һәм уздыруда ярдәм күрсәтергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.4.1. транспорт предприятиеләренә юлларны ябу һәм җәмәгать транспорты маршрутлары үзгәрү турында хәбәр итәргә;

1.4.2. ярышлар маршруты буенча юл билгеләрен урнаштыруда, сүтүдә, каплауда һәм ачуда ярдәм итәргә;

1.4.3. халыкка мәгълүмат җиткерү өчен троллейбусларның контакт челтәре тирәкләрендә юлларны ябу схемаларын урнаштыруны килештерергә;

1.4.4. транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.4.5. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипедлар («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә 2026 елның 11 июлендә 12.00 сәгатьтән алып 2026 елның 12 июлендә 04.00 сәгатькә кадәр әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән участокларда, ярышларны оештыруда ярдәм итү максатыннан файдаланудан

тыш, шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю буенча эшне оештырырга;

1.5. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шайнуров):

1.5.1. ярышлар маршруты буенча ремонт-төзелеш эшләрен үткәрү графигына төзәтмәләр кертергә, ярышларны әзерләгәндә килү юлларын һәм транспорт кую урыннарын төзекләндерү буенча комплекслы чаралар үткәрергә, чара тәмамланганнан соң, аны уздыру урыннары янәшәсендәге урам-юл челтәре объектларын җыештыруны тәэмин итәргә, халыкка мәгълүмат җиткерү өчен юлларны ябу схемаларын яктырту баганаларында урнаштыруны килештерергә;

1.5.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты (И.М.Хисмәтуллин) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитеты (А.В.Сидоров) белән берлектә әлеге карарга 1-4 номерлы кушымталар нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре белән берлектә юлларны йөк техникасы белән ябуда ярдәм күрсәтүне оештырырга;

**2. Тәкъдим итәм:**

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) ярышларны әзерләү һәм уздыру урыннарында җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, Казан шәһәре урам-юл челтәренең күрсәтелгән участокларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү чорында юл хәрәкәте куркынычсызлыгы үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;


2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан шәһәре буенча Сәламәтлек саклау идарәсенә (И.М.Әхмәдиев) ярышларда катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә;

2.3. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) ярышларны әзерләү һәм уздыру чорында күрсәтелгән участокларда транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.


3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**


Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 8 июлендәге
2391 номерлы карарына
1 номерлы кушымта




Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 8 июлендәге
2391 номерлы карарына
2 номерлы кушымта



Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 8 июлендәге
2391 номерлы карарына
3 номерлы кушымта



Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 8 июлендәге
2391 номерлы карарына
4 номерлы кушымта




Юлны каплау өчен техника берәмлеге саны – 87.

Контролер-җаваплы оештыручылар саны – 142.

Дистанциядә хөкемдарлар саны – 38.